ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш); 2024, № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 – 6 өлешләр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Вәкаләтләре срогы тәмамланган Вәкаләтле вәкил билгеләнгән тәртиптә яңа Вәкаләтле вәкил билгеләп куелганга кадәр үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.

5. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре әлеге Законның 6 статьясында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатылганда, билгеләнгән тәртиптә яңа Вәкаләтле вәкил билгеләп куелганга кадәрге чорга Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан, эшкуарлар җәмәгатьчелеге фикерен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручы билгеләп куелырга мөмкин.

6. Вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручыга Вәкаләтле вәкил өчен билгеләнгән таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар кагыла.».

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 01 март
№ 9-ТРЗ